ГЛАВА СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
СОБОЛЕВСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 7 нче йорт, Шиланга авылы,
422577

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

13.11.2019г. с. Соболевское №42

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең Соболевский авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 29 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Соболевский авылы гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2019 елның 29 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Соболевский авылы гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә.

1 этап: Береговая урамы халкы, 1нче йорттан алып 40нчы йортка кадәр

2 этап: Береговая урамы халкы, 41нче йорттан алып 116 нчы йортка кадәр.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне

башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризалыгыгыз бармы?:

- урамнарны яктырту системасын ремонтлау, су башнясы территориясен төзекләндерү

« ӘЙЕ» «ЮК»

5. Гражданнар җыеннарын уздырырга:

   1 этап: Соболевский авылы, Береговая урамы, 30нче йорт адресы буенча урнашкан административ бинада

   2 этап: Соболевский авылы, Береговая урамы, 54нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Югары Ослан муниципаль районының**
**Соболевский авыл җирлеге Башлыгы** **О.Н.Майорова**